че, уйланучы, Коръәннең мәгънәсенә төшенергә тырышучы кеше генә күрәчәк. Аны Бөек Пәйгамбәрләр - Муса һәм Мөхәммәд галәйһиссәләмнәр, һичшиксез, күрәчәк. Кыямәт көнендә "солтан" буласы килгән кеше җирдәге тормышы вакытында акылын һәм йөрәген чистартырга омтылырга тиеш. Аллаһы Тәгаләне күрергә лаек булыр өчен кеше бу дөньяда намусы кушканча яшәргә тиеш. Шул вакытта гына ул Аллаһы алдында бер уч су белән түгел, ә бөтен бер океан булып басып торыр. Бер хәдистә әйтелгәнчә: *"Күкләргә һәм җиргә сыймас хәзинәләр синең йөрәгеңдә саклана"*.

Хакыйкать бары тик Аңа гына билгеле.

*(«Татар мөселман календаре"ннан)*

# Гайбәтнең афәтләре

Бел ки, гайбәт сөйләү күп кешеләрнең теленә хуҗа булган. Аллаһы Үзе саклаган бәндәләр генә гайбәт сөйләүдән имин булыр. Гайбәт сөйләү - бик олы гөнаһ. Аллаһы Тәгалә гайбәт сөйләүчене үлгән кардәшенең итен ашаучыга охшата. Рәсүлуллаһ салләллаһү галәйһи вәсәлләм әйтте: «*Гайбәт сөйләмәгез. Чөнки гайбәт сөйләү зинадан яманрак. Зиначының самими тәүбәсе кабул ителеп, гайбәтченең тәүбәсе, гайбәте сөйләнелгән кеше гафу итмичә, кабул кылынмас*». Янә әйтте: «*Мигъраҗ кичәсендә бер кавем күрдем, битләрен тырнаклары белән ерталар иде. Болар кемнәр, дидем. Дөньяда кешеләрнең гайбәтләрен сөйләүчеләр, диделәр. Сөләйман бин Җәбир әйтә: «Ий Рәсүлуллаһ, миңа мине коткаручы бер гамәл өйрәт», - дидем. Ул: «Үз чиләгеңнән башка берәүнең чиләгенә бер тамчы су салу кебек булса да хәер кылудан баш тартма. Мөселман кардәшләреңә көләч йөзле бул, Сиңа яман булганнарына хезмәт кыл, ерак булганнарының гайбәтен сөйләмә», - диде*». Хак Тәгалә Муса галәйһис-сәламгә вәхи кылды: «Гайбәттән тәүбә итеп үлгәннәр җәннәткә иң соңыннан керерләр. Тәүбә итмичә үлгәннәр җәһәннәмгә иң беренче төшәрләр». Җәбир әйткән: «Рәсүлуллаһ белән сәфәрдә идек. Ике кабер янынннан узганда ул: "Бу каберләрнең икесе дә газапта. Берсе - гайбәт сөйләгән өчен, икенчесе - киемен бәвелдән сакламавы өчен», – диде. Соңыннан агач сындырып алып, ул каберләрнең баш һәм аяк очларына кадады һәм: «Бу агачлар корыганчы аларның газаплары җиңеләер», - диде. Бер кеше үзенең зина кылуын икърар иткәч, Рәсүлуллаһ аны рәҗем кылырга боерды. Сәхабәләрдән ике кеше бер-берсенә: «Аңа эткә таш аткан кебек таш аттылар», – диделәр. Рәсүлуллаһ бер үләксә күреп, аларга моны ашарга кушты. Алар, йә Рәсүлуллаһ, ничек моны ашыйк, диделәр. Рәсүлуллаһ исә: «Ул таш атылган кардәшегезнең ите бу үләксә итеннән яманрак», – диде. Сәхабәләр бер-берсен гайбәт кылмыйлар иде, бу гамәлне монафыйклык, дип беләләр иде. Катадә радый Аллаһа ганһе әйткән: «Кабер газабы өч төрле булыр. Берсе - гайбәт өчен, икенчесе - сүз йөртү өчен, өченчесе - киемен бәвелдән сакламаган өчен».

Гайсә галәйһис-сәлам хавариләре белән эт үләксәсе янынннан үтеп барганда, тегеләр бу нинди сасы исле, диделәр. Гайсә галәйһис-сәлам исә: «Аның нинди гүзәл тешләре булган», – диде. Ягъни ул үзенең иптәшләренә нәрсәгә карасагыз да, аның матурлыгын, яхшылыгын күрә белегез, дип өйрәтте. Бервакыт Гайсә янынннан бер дуңгыз үтеп китте. Ул аңа: «Сәламәт йөре», - дип калды. Аңа: «Йә Рәсүлуллаһ, дуңгызга болай әйтергә ярыймы,» – диделәр. Ул: «Телем хәерле сүз генә сөйләргә тиеш», – диде. Берәүнең хатасы турында сөйләү һәрвакыт гайбәткә санала. Бу сүз үзенә кагылса да, киеменә кагылса да, туганнарына кагылса да, йортына кагылса да һәм башка аның күңелен кыра торган нәрсәләргә кагылса да гайбәткә керә. Рәсүлуллаһ әйтте: «*Бер кеше турында сөйләгәндә, ул кеше моны ишетеп рәнҗерлек булса, бу сөйләшү гайбәт булыр, хәтта бу сүзләр дөрес булса да*». Хәзрәти Гайшә анабыз сөйләгән: «Бер хатын турында аның буе кыска дидем. Рәсүлуллаһ: йә Гайшә, гайбәт сөйләдең, җиргә төкер, диде. Җиргә төкергән идем. Авызымнан бер кисәк кые кан чыкты. Шуны истә тотыгыз: бер әйбер турында сөйләү хәерлегә булмаса, аны сөйләмәгез".

Бел ки, гайбәт тел белән генә сөйләнелми, бәлки, кул белән, күз белән, ишарә белән дә була. Болар барысы да хәрәм. Хәзрәти Гайшә әйткән: «Бер хатынның буеның кыскалыгын кулым белән күрсәткән идем. Рәсүлуллаһ: «Гайбәт кылдың», - диде".

Кешенең йөрүен кабатлап күрсәтү, сөйләвен күрсәтү дә гайбәт була. Кайбер җәһил заһидлар гайбәт кылалар, әмма үзләренең гайбәт кылуларын белмиләр дә. Шуңа күрә гайбәтнең төрләрен һәрвакыт истә тотарга кирәк. Кайвакыт янында гайбәт кылынган вакытта, бу гайбәтне бөтенесе дә ишетсен дип: «Сөбханаллаһ! Бу нинди гыйбрәтле хәл», - диләр. Бу да гайбәт санала. Болай әйтүченең гайбәте монафыйклык белән аралаша, янәсе, ул изге тәкъва кеше, ә үзе гайбәткә көч биреп тора. Кайбер вакыт шулай була, берәү тырышып-тырышып гайбәт сөйли, тыңлаучысы исә теле белән: әстәгъфируллаһ, ди, ә күңеле белән аның сөйләвен яратып тыңлый. Бу да монафыйклык була. Бу вакытта тыңлаучы да, сөйләүче дә гөнаһлы була. Гайбәттән сакланучы кеше үзе янында гайбәт сөйләнелгәндә, гайбәтне туктатырга тиеш, моңа көче җитмәгәндә, ул җирдән китәргә тиеш.

Беркөнне хәзрәти Әбү Бәкер вә хәзрәти Гомәр икәү барганда, берсе: фәлән кеше күп йоклый, диде. Аннары Рәсүлуллаһ янына килеп ашарга сорадылар. Рәсүлуллаһ: «Сез ашадыгыз инде», - диде. Алар хәтерләмибез, диделәр. Рәсүлуллаһ: "Кардәшегезнең итен ашадыгыз, берегез сөйләде, икенчегез тыңлап торды", - диде.

Бел ки, тел белән гайбәт сөйләү хәрәм булган кебек, калеб белән гайбәт кылу да хәрәм. Чөнки бер кешенең гаебен башка кешегә сөйләү ярамаган кебек, аны үз-үзеңә сөйләү дә ярамый. Калеб белән гайбәт итү ул яман зан кылу кебек. Рәсүлуллаһ боерды: «*Хак Тәгалә мөселманның өч нәрсәсен хәрәм кылган: малын, канын һәм аңа яман зан кылуны*». Үзең



9. Мөселман мәчеткә керү белән үзен тиешле тәртиптә тотарга тиеш.

10. Кайбер мәчетләр җомга көнне дин тотучылар белән тулы була. Беркем дә кемнедер торгызырга һәм аның урынын алырга хокуклы түгел. Утыручылардан ягымлы тонда кысылыбрак утыруларын сорарга кирәк, һәр хәрәкәттә, һәр сүздә бер-береңә ихтирам сизелсен.

11. Мәчеткә килүче йокыга китәргә тиеш түгел.

12. Әгәр дә гыйбадәт кылучы үзен йокы басуын сизә икән, бу чакны ул күршесе белән урынын алмаштырсын.

13. Тәннең оят өлешләре күренә торган рәвештә булырга ярамый.

14. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам җомга намазы алдыннан түгәрәк ясап утыруны тыйган. Чөнки бу иркенлекне, урынны киметә һәм сафларның тигезлеген боза.

15. Имам мөнбәрдән вәгазь сөйләгәндә, тыңлаучылар аның күзенә карарга тиеш. Бу – ихтирамлы мөгамәлә билгесе.

16. Имамга Аллаһыдан мөселманнарны ярлыкауны үтенгәндә ялварганнардагы кебек кулларын өскә күтәрү кирәкмиги.

17. Җомга намазы тәмамлану белән чыгарга ашыгырга тәкъдим ителми. Чөнки бу очракта ишек тирәсендә һәм киенгәндә бер-береңә комачаулык килеп чыга.

18. Исламда яһүдләрдәге кебек шаббат төшенчәсе юк һәм мөселманга җомга көнне эштән баш тарту мәҗбүри түгел. Әшне бары тик җомга намазы вакытында гына туктатып тору кирәк.

19. Гыйбадәт кылучы имам хөтбәне башлау белән аны тыңларга, имам сөйләп бетергәнче тын гына утырырга бурычлы. Намазда үзеңне җитди тотмау җомга намазы максатына каршы килә.

20. Җомга көнне генә ураза тотарга тәкъдим ителми. Әмма пәнҗешәмбедән җомгага, җомгадан шимбәгә ураза тоту мөмкин әш.

21. Җомга көнне юлга чыгудан тыелу кирәклеге хакында бернинди дә күрсәтмә юк.

22. Җомга – Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламне искә алу өчен уңайлы вакыт. Бу очракта: «Аллаһүммә салли галә сәйидинә Мөхәммәд вә галә әлиһи Мөхәммәд» («Йә Раббым, Мөхәммәдкә һәм аның гаиләсенә рәхмәтләремне насыйп әйлә»), – дип әйтелә.

23. Һәр җомга Коръәннең «Әл-Каф» (тау куышы) сүрәсен укырга киңәш ителә.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Иренең рөхсәтеннән башка хатыны садака бирә аламы?

Хатын-кыз иренең рөхсәтеннән башка аның шәхси милкеннән яки аларның уртак эшләре нәтиҗәсендә тупланган мал-мөлкәттән садака бирә алмый. Әгәр дә ул ире рөхсәтеннән башка садака бирсә, моның әҗере иренә булачак, ә хатыны исә гөнаһка керәчәк. Әмма әгәр аның иренә бәйле булмаган шәхси мөмкинлекләре, мәсәлән, пенсиясе яки хезмәт хакы һ.б. булса, ул аларны иренең рөхсәтен сорамыйча, ничек тели, шулай файдалана ала. Бу очракта сүз мал-мөлкәт булып саналмаган шырпы, керосин, тоз һ.б. кебек вак-төяк турында бармый. Мондый әйберләрне иреңнең рөхсәтен сорамыйча да бирергә була.

Хатын-кыз өстендә иренең йорты, мал-мөлкәте һәм анда булган бар нәрсә өчен дә җаваплылык ята. Кыямәт көнендә аннан иренең йортын һәм мал-мөлкәтен ничек саклавы турында сорау алыначак.

Пәйгамбәребезнең көрәштәше һәм ике туган энекәше Гали: «Кешенең бәхете биш әйбергә: хатынының буйсынучанлыгына, балаларның дингә ышанучанлыгына, дин кардәшләренең динаятьлелегенә, күршеләренең яхшылылыгына һәм үзе яшәгән җирдә яшәү өчен кирәкле чараларны табуына бәйле», - дигән. Мондый тәэсеклеккә һәм бәхеткә Аллаһы Тәгалә бәхеттән өлеш чыгарган кешеләр генә ия. Ирләренең кулына таякны кайвакыт хатыннар үзләре тоттыралар. Хатын-кыз өчен иренең кулына әлеге таякны бирмәскә һәм сугылуга дучар булмаска тырышудан да яхшырак чара юк. Ирең белән әрләшкәнче, Аллаһы Тәгаләнең фиргавен хатыны Асияне иренә буйсынучанлыгы өчен нинди дәрәҗәгә лаек кылуын карау яхшырак. Әгәр эчүче ирең белән әрләшсәң, бу гаилә таркалу белән яный, ә моның нәтиҗәсендә балалар әтиләренең игътибарыннан һәм кайгыртуыннан мәхрүм калалар. Хатын иренә аның үз-үзен тотышыннан канәгать булган өчен генә игътибар күрсәтергә тиеш түгел. Аны тәрбиялап, ул ихластан Аллаһыга: «Әй, Аллаһым! Син аны күрәсең һәм тәртибе турында беләсең! Аллаһы Тәгаләм, Синең ихтыярыңа буйсынып, һәм аңа ярашлы рәвештә ирем алдындагы бурычымны үтәргә тиеш булганлыктан, мин аны тәрбиялим», - дип мөрәҗәгать итәргә тиеш. Асия фиргавенне нәкъ менә шул рәвешчә караган. Әгәр хатыны әлеге ният белән иренә буйсынса, аның буйсынучанлыгын күреп, Аллаһының ризалыгы белән ире яхшы якка үзгәрергә мөмкин. Әгәр хатыны һәрвакыт ризыкны тәһарәтле килеш әзерли икән, бу, һичшиксез, иренә начар сыйфатлардан арынырга ярдәм итәр.

Һәм иргә үзен аның өстеннән югарыдан идарә итүче булмаган җитәкче кебек тотарга ярамый. Ул рөхсәт ителгәннең чикләрен сакларга тиеш. Үзләренең көче һәм идарәсеннән файдаланып, ир-атларга хатын-кызлар өстеннән мыскыл итү рөхсәт ителми. Аллаһы Тәгаләнең кануннары буенча алар ир-атларга ышанып тапшырылган хәзинә

№ 14 (1193), 30 март 2013 ел